РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.07.2021 № 845-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә агынты суларны агызуны (читкә чыгаруны) гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агынты сулар составы нормативларын раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Салкын су белән тәэмин итү һәм су чыгару кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Агынты суларның составын һәм үзлекләрен тикшереп тору кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында” 2020 елның 22 маендагы 728 номерлы карары нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә пычратучы матдәләрнең тискәре йогынтысын, су объектларының пычрануын кисәтү максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә агып төшүче суларны агызуны (читкә чыгаруны) гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агып төшүче сулар составының нормативларын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә агып төшүче суларны агызуны (читкә чыгаруны) гамәлгә ашыручы барлык абонентларга агып төшүче сулар составының нормативларын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2021 елның
14 июлендәге 845-п номерлы
карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә агып төшүче суларны агызу (читкә җибәрүне) гамәлгә ашыручы абонентлар өчен агып төшүче сулар составы нормативлары

| № т/б | Пычраткыч матдәләр исемлеге | Агып төшүче суларның составы нормативлары, мг/дм3 |
|---|---|---|
| 1 | Алюминий | 0,08 |
| 2 | Аммоний-ион | 225 |
| 3 | АСПАВ | 15 |
| 4 | БПК5 | 565 |
| 5 | Ванадий | 0,001 |
| 6 | Үлчәнгән матдәләр | 300 |
| 7 | Тимер | 9 |
| 8 | Кадмий | 0,0001 |
| 9 | Кальций | 129 |
| 10 | Кобальт | 0,02 |
| 11 | Марганец | 0,02 |
| 12 | Бакыр | 0,003 |
| 13 | Нефть продуктлары | 0,17 |
| 14 | Никель | 0,024 |
| 15 | Нитратлар | 40 |
| 16 | Нитритлар | 0,8 |
| 17 | Кургаш | 0,002 |
| 18 | Сульфат-анион | 106 |
| 19 | Сульфид-анион | 0,20 |
| 20 | Коры калдык | 1 650 |
| 21 | Фенол | 0,053 |
| 22 | Формальдегид | 0,039 |
| 23 | Фосфат-ион (Р буенча) | 34 |
| 24 | Фторид-анион | 0,223 |
| 25 | Кислородны химик куллану, ХПК | 1 650 |
| 26 | Хлорид-анион | 140 |
| 27 | Хлороформ | 0,0032 |
| 28 | Хром 3+ | 0,01 |
| 29 | Хром 6+ | 0,04 |
| 30 | Цинк | 0,042 |

Искәрмә:

1.Майлар һәм нефть продуктлары канализация системасына эретелгән һәм эмальгацияләнгән хәлдә генә агызыла.

2. Исемлектә күрсәтелмәгән пычраткыч матдәләрне хуҗалык-эчәргә яраклы һәм балык хуҗалыгы кулланышындагы сулыкларның тиешле-чик концентрацияләреннән (ТКК) артмаган концентрацияләрдә ташлау рөхсәт ителә (ТККның минималь кыйммәте буенча).